# БЕР КАЛЫПКА ГЫНА САЛЫРГА ЯРАМЫЙ



**(Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Һәм дуңгыз ите җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатында бу ел башында «Норлат» агрофирмасы төзедек. Аның составына ачык типтагы «Норлат -Октябрь ит комбинаты» акционерлык җәмгыяте, Синдряков исемендәге, «Рассвет», Якты Күл крестьян хуҗалыклары ассоциацияләре кертелде. Хәзер агрофирма итне җитештерү белән дә, аны эшкәртү һәм сату белән дә үзе шөгыльләнә.

Элек дуңгызчылык комплексы катнашазыкны Норлат - Октябрь элеваторыннан сатып ала иде. Моннан ары комплексның бу төр азыкка булган ихтыяҗын аның үз заводы канәгатьләндерәчәк, азык инде хәзер үк 40 процентка арзанрак та.

**Реформалауның өченче юнәлеше** таралып бетә язган һәм банкротлык чигенә килеп җиткән алты хуҗалыкны, хезмәт коллективларының ризалыгы белән, агроцехлар оештыру өчен промышленность предприятиеләре һәм төзелеш оешмалары балансына бирү булды. Кыска гына вакыт эчендә аларда җитештерү һәм хезмәт дисциплинасы торышы,җитештерү культурасы һәм эшнең нәтиҗәләре сизелерлек яхшырды. Мисал өчен, шикәр заводы агроцехында бүген көнлек савым 12,5 килограмм тәшкил итә һәм бу узган елгыдан 8,4 килограммга күбрәк.

**Реформалауның дүртенче юлы** - колхозларның үзләре эчендә тулы хуҗалык исәбендә, мөстәкыйль балансы һәм банкта үз счеты булган, хезмәтне оештыруның нарядсыз системасы ,эшләүчеләргә ай саен аванс биреп барып, ел ахырында тулы исәп - хисап ясау юлы белән авыл хуҗалыгы кооперативлары оештыру.

Норлат -Октябрь сөтмай комбинатының «Илюткинское» агроцехында тәмамланган цикл белән өч кооператив төзелде, ягъни аларга һәр кооператив терлек азыгын да үзе җитештерерлек һәм терлекчелектәге эшнең нәтиҗәләре белән кызыксынырлык иттереп җир пае, техника һәм терлек тапшырылды. Кооперативларга хуҗалыкның элеккеге рәисе, баш инженеры һәм баш агрономы җитәкчелек итәләр. Һәр кооперативның район хакимиятендә расланган Уставы, банкта үз счеты бар. Язгы чәчү һәм урып - җыю чорында кооператив рәисләре үзләре дә техникага утырып эшләячәкләр. Кооперативлар эшчәнлеген «Норлат-Октябрь сөт-май комбинаты» АҖ генераль директоры координацияли. Кооператив җитәкчеләре эшкә зур теләк һәм рухлану белән тотындылар, бөтен халык эштә. Кирәк булганда механизаторлар терлекчеләргә ярдәмгә киләләр.

**Реформалауның бишенче варианты**- хуҗалык исәбендәге аренда звенолары оештыру. Бу яктан «Заря» крестьян хуҗалыклары ассоциациясен мисалга китерергә була. Аның рәисе итеп фермер И.Тәмаев сайланды. Аның тәкъдиме буенча бирегә аларга җир, техника һәм маллар беркетелеп өч звено төзелде. Монда звеноларның берсен рәис үзе, икесен баш агроном һәм баш инженер җитәкли.

Крестьян хезмәтен оештыруның **фермер хуҗалыклары төзү** кебек формасы да игътибардан читтә калмый. Әлегә алар районда 14 һәм аларга 668 гектар авыл хуҗалыгы файдалануы җире, шул исәптән 484 гектар сөрүлек җир беркетелгән.

**Җиденче юнәлеш** - гражданнарның шәхси хуҗалыгын үстерү. Әлегә ул җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Әйтик, урман эчендәге Торнояс поселогында терлек асрау өчен зур мөмкинлекләр бар, әмма 80 хуҗалыкта нибары 85 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән 70 сыер, 82 дуңгыз һәм 136 сарык асрыйлар, ә җәмәгать секторында бер баш та мал юк. Шуңа күрә ике секторда да терлек асрауны киңәйтү максатыннан бу поселокта «Агробанк»ның Норлат - Октябрь бүлекчәсенең ярдәмче хуҗалыгын оештырдык. Хәзер анда булган абзарларны дуңгыз асрауга үзгәртеп кору бара, ана дуңгызлар, шәхси хуҗалыкларга атлар һәм мөгезле эре терлек кайтарыла.

Районда колхоз - совхозларны үзгәртеп кору, авыл кешеләренең хезмәтен оештыру мәсьәләләренә яңача мөнәсәбәтнең нәтиҗәләре өмет уята. Әйтик, район терлекчеләре дәүләткә сөт һәм ит сатуның беренче квартал заданиеләрен вакытыннан алда үтәделәр. Контрактация килешүендә каралган 37 мең центнер урынына дәүләткә 40560 центнер сөт, җиткерелгән 8800 урынына 9704 центнер ит сатылды.

Халык бу үзгәрешләрне хуплый. Хуҗалыкларны берләштерү яки аеру хәзер элеккеге төсле иясезлек шартларында түгел, ә шәхси милек нигезендә алып барыла бит. Һәм продукция җитештерүне арттыру да авыл халкының матди хәлендә турыдан туры чагылыш табачак: ул үзенең җир кишәрлеге һәм милек пае өчен көзен ашлык, печән, салам, төрле хезмәтләр рәвешендә аренда түләвен дә күбрәк алачак.Ә инде матди муллыкның җитештерү подразделениесе эшчәнлегенең ахыр нәтиҗәләре белән турыдан туры бәйләнештә икәнлеген аңлау аны сакчылрак булырга һәм уйлап-исәпләбрәк эш итәргә этәрә. Аграр реформаның төп асылы да шунда түгелме соң инде?

**(«Республика Татарстан»ның быелгы 2 апрель санынннан).**

Авылда кемне хөрмәт итәләр? Билгеле инде, тырыш, тәртипле кешене. Йосыф Шиһапович та якташлары арасында абруйны тырыш хезмәте белән яулады дисәк, һич арттыру булмас. Ул көтүне тулыландыру буенча технолог. Күп нәрсәне белергә омтылган, эшкә үҗәт Йосыфны хуҗалыкта технолог итеп билгеләгәндә, махсус белеме юк иде әле аның. Аннан үз инициативасы белән ул Чистайда курслар тәмамлап, практик тәҗрибәсе теоретик яктан да ныгытты. Хезмәтенең югары нәтиҗәлелеге дә шул турыда сөйли: «Рассвет» КФХАндә маллар тулысынча ясалма орлыкландырыла. Йосыф Шиһапович һәр малның буазлыгын билгеләү өчен ректаль тикшерүләр үткәрә, малларны даими күзәтү астында тота.

Йосыф районда технологлар белән уздырылган бер генә чарадан да читтә калмый. Бер еллап элек үткәрелгән конкурста ул 30лап технолог арасында III нче урынны яулады. Комиссия әгъзалары Йосыф Шиһаповичның барлык сорауларга биргән практик мәгълүматларга бай, төгәл җавапларын бик ошатканнар иде ул вакытта. Бераз соңрак Фәйзуллин республика күләмендә үткәрелгән шундый бәйгедә дә катнашып, яхшы нәтиҗә күрсәтте.

**Рәсемдә: «Рассвет» КФХАсы технологы Й.Фәйзуллин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# Картаймасаң - гомер узмый ул

***Илле дүртенче елның кызу урак өстендә көпә - көндез янып киттеләр алар. Тупланган бар мал - мөлкәт санаулы минутлар эчендә көлгә әйләнде. Бишектәге бала - Минияэны ходай үзе коткарып калгандыр инде, мөгаен. Сыек төтен пыскып утырган йорт урыны, тирә - якка таратып ыргытылган кара агач кисәүләренә карап, озак басып торды Хатыйп: торырга йорт, кияргә кием, ашарга ризык юк. Ничек яшәргә?:***

***- Нихәл, яшьти?***

***Хатыйп уйга батып янына мотоцикл килеп туктаганын да ишетмәгән икән.***

***- Менә күз алдында,- диде ир тамак төбендәге тирән йотып һәм кесәсенә тыгылган кулын чыгарды - бөтен калган әйбер менә шул һәм... 5 бала.***

***Хатыйпның ярганалып, сөялләнеп беткән кытыршы зур учында 10 тиен көмеш ялтырады.***

***- Нык бул, дускай,- диде Вазыйх. - Иң мөһиме, үзең, балаларың исән, кайгыңны бергәләп җиңәрбез...***

Дуслар тыйнак итеп кочаклаштылар. Нәкъ сугыш елларындагыча... 1946 нчы елда хәрби хезмәттән демобилизацияләнгәндә действительный хезмәте сугыш елларына бәйләнеп, 7 ел өендә булмаган Хатыйп өен, үзе киткәч туган кызы Миңсылуын никадәр сагынса да сугышчан дусты, якташы Вазыйхны бергә кайтыр өчен 13 көн буе көткән иде бит. Их, ул көннәр! Туганлыкның, дуслыкның бәясенә шул елларда төшенде Хатыйп. Авыр сугыш елларында башланып ныгыган дуслыкны үзләре генә түгел, балалары да дәвам итерә. Икенче буын өчен зур үрнәк булды бу.



Бүген йөрәктә дәрт сүрелмичә, буыннарда дәрман беткәндә шушы авыр фаҗигадән соң көн - төн урманнан агач ташулары, санаулы көндә балалары белән гүрнәчәй кебек йортка кереп утыруына үзе дә гаҗәпләнә. Хәер, җилкәсендә бүрәнә ташып үз гомерендә 5 йорт җиткезгән кеше өчен моның әллә ни искитәрлек нәрсәсе дә юк кебек бүген. Дусты Вазыйх, туганнары булды шул янәшәдә. Аннары балаларын яхшы шартларда яшәтү теләге көчле булуы да бөтен киртәләрне җимерерлек иде.

Хатыйп аганың яшьлек җегәрлеген авылда әле дә хәтерләүчеләр бар. Берьюлы тегермән тарттыра, агач ярдыра, кичен халыктан сөт җыеп аны Норлатка да илтергә өлгерә иде. Әле күпме гомер җәйләрен сугыш чорында үтәгән хезмәте - пешекче вазифасын да башкарды: йокы, ял дигән нәрсә аның өчен ят иде.

- Әтинең эштән туры өйгә кайтканын хәтерләмибез,- дип искә алалар бүген балалары - йорт, мал - туарны карап әйләнмәсә күңеле тынычланмый иде.

- Андый гадәтем бар инде,- дип кеткелди Хатыйп ага,- ә өй өчен җаным һәрчак тыныч иде - әниегез барысын да булдыра, барысына да өлгерә иде.

Әйе, өе өчен җаны тыныч булмаса, шулай үзен бөтенләе белән эшкә багышлый алыр идемени?! 1972 нче елда Якты Күлдә булып Хатыйпның тегермән «җаны» саклаучы булапак җитезлегенә, өлгерлегенә сокланга[н], аның турында байта[к] уңай фикерләр ишеткән КПСС райкомының беренче секретаре Г.К.Гыйматдинов район фондыннан «Урал» мотоциклы бүләргә боерган иде үзенә.

Гаилә шулай тыныч кына, тигез яшәде. Хатыйпның җитезлеге, Мәрхәбәнең сабырлыгы бер - берләрен тулыландырып тордылар. Балалар санының сигезгә җитүенә дә әллә ни көенмәделәр: үз бәхетләре белән туалар дип шөкерана кылдылар. Ә алар исә, кем әйтмешли, тәгәрәшеп үстеләр. Кул арасына кергән берсе әти - әнисе янында булды. Кызлар әниләренә чөгендер эшкәртергә булышсалар, малайлар әтиләренең бөтен эшендә ярдәмче булдылар: көннәрен тегермәндә, агач ярдыру цехында үткәрделәр, кызларының иң чаясы - Миниязы әтисе белән Норлатка сөт илтергә йөрде, бидоннар юу исә калган кызлар өстендә булды. Өлкәнрәкләр кечеләренә күз - колак иделәр.

# Ач күзеңне, дөнья бу!

# ЙОМГАК ЯСАЛДЫ



Быелның 3 аенда район территориясендә 7 юл - транспорт фаҗигасе булды, аларда 2 кеше үлде, 5се яраланды. Узган елның шул чоры белән чагыштырганда бу саннар һәммәсе үсте.

23 гыйнварда МППдан В.Казаков УАЗ - 469 автомашинасында гражданка П.ны бәрдерә, соңгысы тән җәрәхәте ала.

27 гыйнварда «Правда» КФХАсы терлекчесе Л.Совков җиккән аты белән исерек килеш КамАЗ машинасына бәрелә, нәтиҗәдә үлем җәрәхәте ала.

9 февральдә Зүзәй НГДПсыннан КамАЗ - 53212 автомашинасы шоферы Б.Корнеев артка чигенгәндә машинасы белән Р.Сәләхетдиновка бәрелә, соңгысы фаҗига урынында һәлак була.

Шул арада юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучы 3000 кеше мәгълүм булды. 100дән артык кеше автотранспорт белән исерек килеш идарә иткәндә тотылдылар. Алар арасында НУРБдан Ю.Степанов, В.Гордеев, И.Мөхәрмәтов, А.Евставьев, М.Галләмов, А.Фәсхетдинов, В.Спиридонов, УТТдан А.Михеев, А.Садретдинов, Б.Вәлиуллин, М.Шаһапов, А.Илеверов, Т.Игътисамов, МППдан И.Фәхретдинов, Р.Яруллин, Ф.Мостафин бар иде.

Бу чорда штраф стоянкасына 300ләп транспорт куелды.

Узган елдан бирле штраф стоянкасында 65 мотоцикл тора, ияләре алар хакында онытканнар да бугай. 10 апрельдән ГАИ салым инспекциясе белән берлектә бу мотоциклларны сата башлый.

Аварияләрнең күбесе автомототранспорт йөртүчеләр гаебе белән булса да, автомобиль юлларының торышы да үз йогынтысын ясамый калмады. Норлат - Чистай автоюлында Чирмешән һәм Сөлчә елгалары аша күперләр авария хәлендә кала бирә. Барлык тимер юл кичүләрендә юл билгеләрен яңарту таләп ителә.

Шәһәр эчендә юл үткәргеч шулай ук авария хәлендә. 1996 елда юлүткәргечтә тимер юлның төньяк өлешендә НУАД тарафыннан коймалар алыштырылган иде. Әмма аның көньяк өлеше куркынычсызлык кагыйдәләренә җавап бирми: биредә коймалар бөгелгән, тартылган. Шул участокта кыш көне 2 юл - транспорт фаҗигасе булды, бәхеткә, ул әле корбаннарсыз үтте.

Линейная һәм Куйбышев урамнарында тротуар, яктырткычлар булмау да куркыныч тудыра.

Шәһәрнең юл билгеләре белән тәэмин ителеше ихтыяҗның 20 проценты күләмендә генә. Күп гражданнар безгә өйләре янында теге яки бу юл билгесе куюны үтенеп мөрәҗәгать итәләр. Бүгенге көндә бер юл билгесе бәясе 300 мең сум тора, ә үзәкләштерелгән билгеләр кую башкарылмый.

Юлбилгеләре алу, светофорлар чыгымнарын түләү өчен Норлат шәһәре үзидарә Советы средстволар бирми. Мондый караш якын киләчәктә юл чатларында светофорларның баганасы гына калуга китерергә мөмкин.

1 апрельдән автомобиль юлларын җимерелүдән саклау максатында хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертелде. Кызганычка каршы, күп шоферлар бу положениене бозалар.

Тагы бер нәрсә. 3 айда балалар катнашында 2 юл фаҗигасе булды, анда 2 бала тән җәрәхәте алды.

Хәзерге вакытта безгә 5 картинг бирелде, анда укучылардан картингистлар туплау бара.

**Х.ӘЮПОВ,**
**ГАИ начальнигы, милиция майоры.**

# Ут алган гомер

Кеше гомере иң кадерле нәрсә, дибез. Ләкин кайбер очракларда бигрәк тә киләчәген үлем куркынычы астына куеп ут чыгуга битараф караучыларны күрәсең дә, бу фикер белән килешеп тә булмый. Янгыннарның сәбәбе гадәтигә әйләнде - саксызлык, балалар шуклыгы, мичләрне урнаштыру һәм файдалану кагыйдәләрен бозу.

Янгында һәлак булучыларның күп өлешен исерекләр, ялгызлар һәм картлар тәшкил итә. Үлем очраклы янгыннарның 75 проценты торак йортларга туры килә. Быелның беренче кварталында гына районда 18 янгын очрагы булды. Шуларның икесендә кешеләр һәлак булды.

1997 елның 11 гыйнваренда Абляскино авылында Л.Н.Матвеев хуҗалыгында янгын чыга. Янгын 73 нче һәм 48 нче янгын частьләре көче белән сүндерелә. Л.Н.Матвеев каты пешүләрдән район үзәк шифаханәсенә барганда вафат була.

1997 елның 14 мартында төнге сәгать 3 тулганда Иске Чаллы авылыннан янгын чыгу хәбәре алына. Шул ук янгын частьләре янгын урынына килеп җиткәндә ут йортны тулысынча камап алган була. Сүндергәндә гражданин Н.И.Синдряков мәете табыла.

Янгыннар очраклы гына килеп чыкмый, бу хакыйкать янгын саен раслана. Әмма янгыннарның, анда үлемнәрнең һәркайсына игътибарсызлык һәм янгын куркынычсызлыгына җитди караш булмавы хас.

**Р.ӘХМӘДИЕВ.**
**73 нче янгын часте өлкән инспекторы.**

Шахмат Шахмат

## Анда да, монда да без җиңдек

Шәһәребезнең шахмат буенча ир-атлар командасы белән Аксубай шахматчылары арасында иптәшләрчә очрашулар үкәрү матур традициягә керде инде. Быел да уздырдык андый очрашуны. Башта безнең 14 кешелек команда Аксубайга барды. Үзара килешү буенча һәр уенчы икешәр партия үткәрде - аклар һәм каралар белән. Кайбер партияләргә сәгатьләр дә кабызылды. Уен бик киеренке барды, шуңа да кайсы команданың җиңәчәге ахырга кадәр диярлек билгесез булып кала килде. Менә соңгы партияләр дә уйналды һәм бәхеткә каршы гомуми нәтиҗә безнең файдага 14,5 : 13,5 булып чыкты.

Икенче атнада, ә ул очрашу сайлау көнгә туры килде, инде аксубайлылар үзләре безгә килделәр. Ике командада да кайбер үзгәрешләр ясалган иде, уенчылар саны да 16 шарга җиткерелде. Уен тәртибе элеккечә үк калды. Әмма, эт үз оясында көчле диләр бит. Шуның рәхмәтедер инде, бу юлы очрашу тагын да зуррак исәп - 20 : 12 аермасы белән тагын безнең файдага тәгәлләнде. Уенда катнашкан барлык шахмат осталарыбызга рәхмәттән башка сүз юк.

Мондый очрашуларны алга таба да дәвам иттерергә дип килештек.

**А.Костин.**


## «Татнефтепром» АҖе акционерларның еллык җыелышы үткәрелүе турында хәбәр итә.

**Хөрмәтле акционерлар!**

Җыелыш 1997 елның 25 апрелендә иртәнге сәгать 10да «Карабашнефть» НГДУсы бинасында була. Адрес: Бөгелмә районы, Карабаш эшчеләр поселогы, «Карабашнефть» НГДУсы.

Җыелышта катнашырга хокуклы акционерларның исемлеге 1997 елның 28 мартына булган мәгълүматлар буенча төзелде.

Җыелышта катнашучы акционерларны теркәү иртәнге сәгать 7дән 9га кадәр үткәрелә. Үзең белән паспорт, ә акционерларның вәкилләренә аларга җыелышта катнашу хокукы тапшырылу турында ышанычлама алып килергә кирәк.

Көн тәртибе:

1. Санау комиссиясен оештыру.
2. Җыелышны алып бару тәртибе турында нигезләмә раслау.
3. Ревизия комиссиясе турында нигезләмә раслау.
4. Җәмгыятьнең уставын раслау.
5. Җәмгыятьнең еллык хисабын, бухгалтерлык балансын, табышлар һәм чыгымнар хисабын, табышын бүлүне раслау.
6. Акцияләр буенча дивидендлар күләмен раслау.
7. Директорлар советы членнарын сайлау.
8. Ревизия комиссиясе членнарын сайлау.

Җыелыш үткәрү һәм аның көн тәртибенә кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча да сораулар белән директорлар советына мөрәҗәгать итә аласыз. Адрес: Әлмәт шәһәре, К.Цеткин ур., 30, «Татнефтепром» АҖ бинасы, тел.: 3 - 35 - 22.

«Татнефтепром» АҖ директорлар советы.


# КОТЛЫЙБЫЗ!



Биккол авылында яшәүче **Шәйхетдинова Минзада Шакировнаны** 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз. Әниебезгә озын гомер, исәнлек телибез.

***Җәрия, Минәхмәт, Лилия, Ленар, Әлфис, Роберт.***



*8 апрельдә Биккол авылында яшәүче кадерле кызым* ***Гүзәл Виль кызы Кәримованың*** *туган көне булды. Шул уңайдан аны чын күңелемнән котлыйм. Саулык - сәламәтлек, бәхет һәм шатлыклар, озын гомер телим.*

***Әниең.***

# БЕЛДЕРҮЛӘР


## Сатабыз

**Яңа «Ока - 1113», кыйммәт түгел.** Адрес: Красноармейская ур., 63 - 9.

***

**Аэропорт янында базы белән гараж.** Тел.: 2 - 29 - 28 (кичке 6дан 11 гә кадәр).

***

**1996 елның августында чыккан, гранат төсендәге ВАЗ - 21093.** Адрес: Кошка авылы, 60 лет Октября ур., 42, тел.: 2 - 28 - 34 (8 - 250) 2 - 12 - 56.

***

**Биләр Озерода дача өчен 20 сутый бакчалы иске йорт (кыйммәт түгел)**. Тел.: 2 - 26 - 25.

***

**1979 елгы ВАЗ - 2101.** Адрес: Промышленная ур., 18 - 3 (кичке 5тән 8гә кадәр).

***

**Кормыш ягында 3 бүлмәле фатир**. Тел.: 2 - 21 - [illegible] (кичке 6дан соң).

***

**Икешәр кв. метрлы цинкланган түбә калае. Кабыргалысы 55 мең сум, шомасы 50 мең сум**. Тел.: 2 - 13 - 69.

***

**25ле торба**. Тел.: 2 - 24 - 99.

***

**Норлатта ашыгыч төстә 2 бүлмәле фатир**. Самарада тел.: 58 - 37 - 65.

***

**1983 елгы әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21013.** Адрес: Школьная ур., 57 (теләсә кайчан).

***

**Әфган поселогында төзелеп бетмәгән йорт, арзанайтылган бәягә.** Адрес: 60 лет Октября ур., 9 - 4 (кичке 5тән соң).

***

**«Геофизика» бакчачылык җәмгыятендә 7 ел карап тотылган дача участогы.** Тел.: 5 - 20 - 42 (кичке 4тән соң).

***

**Оешма комплектта яки аерым - аерым ат сбруйлары сата.** Адрес: Кошка авылы, 60 лет Октября ур., 42, тел.: (8 - 250) 2 - 12 - 56.

***Норлат - Октябрь сәүдә базасы төрле чит ил фирмалары чыгарган көнкүреш техникасын: үтүк, кыска дулкынлы мич һ.б. (барлыгы 36 төрле) киңәйтелгән сату үткәрә.***

**Бездән товарлар сатып алырга чакырабыз.**

## Сатабыз яки алмаштырабыз

**2 бүлмәле фатир сатыла яки - өстәмә түләп бер бүлмәлегә.** Адрес: Чапаев ур., 9 - 10 яки 9 - 17.

## Фатир эзлим

**Шәһәрнең үзәк мәйданы тирәсендә бөтен уңайлыклары булган ике бүлмәле фатир кирәк. Телефон, кайнар су (газ колонкасы), төсле телевизор, йомшак мебель, барлык уңайлыклар булуы шарт.** Тел.: 2 - 18 - 61, 2 - 23 - 10, 2 - 22 - 60 (эш көннәрендә генә иртәнге сәгать 10нан 12 нче яртыга һәм көндезге 1дән 4кә кадәр.

## Эшләп бирәбез

**Үзебезнең материалдан теләсә нинди зурлыкта бура бурап бирәбез.** Тел.: 4 - 42 - 10 (кичке 4тән соң).

***

***Әгәр сез үзегез «Кодак» тасмасына фотосурәткә төшерәсез һәм аны ачыгайту һәм фоторәсемнәр ясау мөмкинлегегез юк икән, ярдәм сорап безгә, «Техника» кибетенең икенче катында телевизорлар сата торган бүлеккә мөрәҗәгать итә аласыз. Биредә шулай ук фототасмалар, фотоаппаратлар да сатыла, тәҗрибәле фотограф киңәшләр бирә.***



Лицензиябез сер. А - 96 № 104210.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. 6574